

ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК ,ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!

№1 Сентябрь Октябрь

2020 нче ел

# МӘКТӘП СУЛЫШЫ

*Гыйлемлелек - инсаннарны мәңге яшәтә торган “тереклек суы” ул. Ансыз һөнәр дә, бәхет тә юк.*

*У.Имәни*




***Хөрмәтле Укытучыларыбыз!***


***Сезне һөнәри бәйрәмегез белән ихластан кайнар котлыйбыз! Сезгә корычтай нык сәламәтлек, гаилә бәхете, һәр туачак таңга сөенеп имин тормышта яшәвегезне теләп калабыз.***

***Сезгә карап сокланабыз һәрчак<br>Күңелләрдә туа горурлык.<br>Рәхмәт сезгә, әле ярый сез бар<br>Безгә үрнәк булып торырлык!***



*Укытучы, мәктәп... Гомер узган саен бу сүзләрне гел искә төшерәбез. Шушы сүзләрне ишеткән саен, балачакка, мәктәп елларына кире әйләнеп кайткан кебек булабыз. Нәкъ җырдагыча, хәтерлим мин әле бүгенгедәй...*

**Абрамов Сергей Александр улы, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы:** «Без мәктәпкә урман аша 7 чакрым җәяү йөрдек. Миңа мәктәптә уку бик ошый иде. Хәзер дә мәктәп елларын сагынып искә алам.»





**Вильданова Ильмира Фәнис кызы, математика укытучысы:** «Мәктәптә укыган вакытта без бәрәңге җыярга йөрдек. Бу безгә бик ошый иде. Йөк машинасының арбасына утырып, җырлый-җырлый басуга барып җитә идек. Күңелле итеп ярыша-ярыша бәрәңгене җыеп, машина арбасын тутырып куябыз. Укытучылар программадан артта калабыз дип кайгырсалар да, безнең өчен ул бер зур бәйрәм кебек иде.»



**Кутлиева Светлана Рәшит кызы, рус теле һәм әдәбияты укытучысы:** “Мин мәктәптә бик актив укучы булдым. Без мәктәптән өйгә кайтып киткәнче, караңгы төшеп бетә иде. Мәктәп газетасының баш мөхәррире булдым. Төрле мәкаләләр, шигырьләр язарга бик ярата идем. Шуңа күрә дә мин укытучы һөнәрен сайладым.”

**Хафизова Дамира Мөнир кызы, рәсем һәм җыр укытучысы:** “Башлангыч сыйныфта без 46 укучы укыдык. 1 нче сыйныфта укытучы апабыз яхшы укучыларга йолдызлар бирә иде. Шул йолдызларны алу өчен, без тырыша идек. Мин мәктәптә “4”, “5” билгеләренә генә укыдым.

*Әңгәмәне Колесникова Юлия һәм Гәделшина Полина алып бардылар.*

*Тәмле булсын*

***Бүген бәйрәм табынына гөбәдия әзерлибез. Гөбәдия** – татар халкының табын күрке булган милли ризыкларының берсе. Гөбәдияне ачы камырдан да, төче камырдан да, ит белән дә, җиләк-җимеш белән дә ясыйлар.*

**Җимешле гөбәдия:**

Камыр өчен: 0,5 стакан җылымса суга бер аш кашыгы ак май, бер аш кашыгы сыек май, бер йомырка, ике аш кашыгы шикәр комы, бер чәй кашыгы тоз (тутырмыйча), 6 гр дрожжи салып яхшылап болгатып, 300-350 гр он кушып, йомшаграк камыр басабыз һәм 30 минут ял иттерәбез.

Эчлек өчен: 300 гр бераз гына тоз салып бүрттерелгән дөге, 300 гр корт, 3 аш кашыгы шикәр комы (75 гр), 200 гр ак май, 4 пешкән йомырка кирәк.





Камырны әзер булгач, майланган табага җәеп салабыз, майлыйбыз һәм төбе җебемәсен өчен юка гына итеп бүрттергән дөге салабыз. Аның өстенә кортны җәябез, тагы дөге, аннары вакланган йомырка һәм яңадан дөге салабыз. Дөге өстенә йөзем җимешен тезеп чыгабыз. Май сипкәч, камыр белән өстен каплап, кырыйларын ябыштырабыз һәм матур итеп бөрәбез. Өстенә онга бераз шикәр комы һәм май уалап валчык ясап сибәбез. Газ мичендә 180 градуста 35-40 минут пешерәбез.

***Бәйрәм сыебыз әзер! Ашларыгыз тәмле булсын!***









# “Укытучыма әйтер сүзем бар” акциясе

Илһам чишмәсе

### Беренче укытучым!

Һәр кешенең иң матур, иң татлы һәм җылы истәлекләре аның балачагы белән бәйләнгән була. Иң күңелле хатирәләр, әлбәттә, мәктәп еллары. Мәктәп дигәч, күз алдыма шунда ук беренче укытучым - Ләйлә Фәнис кызы килеп баса. Ул кулыбызга каләм тотып язарга, беренче белем серләрен үзләштерергә өйрәтте. Укытучым биргән белем һәм киңәшләр безгә гомер буе кирәк булачак. Ләйлә Фәнис кызы –белемле, таләпчән, гадел укытучы. Мин аңа һәрчак сокланам һәм хөрмәт итәм. Аңа эшендә уңышлар һәм сәламәтлек телим!

Хәйретдинова Амалия, 9нчы Б сыйныфы укучысы.

### Укытучы-изге һөнәр иясе

Дөньяда һөнәрләр бик күп. Аларның төрле һәм кызыклы булуы турында һәркем белә. Шулар арасыннан изге һөнәр ияләре - укытучылар турында сөйлисем килә. Алар шәхес тәрбияләүче, укучыларга белем бирүче. Укытучыларыбыз һәр бала белән уртак тел таба белә. Иртән балалар мәктәпкә килгәндә елмаеп, якты йөз белән каршы алалар. Укытучылар гадел, сабыр кешеләр. Балаларны ярhaталар, белемле һәм тәртипле булуларын телиләр. Һәр укытучының дәресе кызыклы, мавыктыргыч уза. Дәрес саен- яңа ачышлар. Алар барлык сорауларга да җавап таба беләләр. Минемчә, мондый дәресләр һәм мондый укытучылар булганга күрә укучылар рәхәтләнеп укыячаклар, белем алачаклар. Барлык укытучыларга да авыр, ләкин мактаулы эшләрендә уңышлар телим!

Хафизова Азалия,

9нчы Б сыйныфы укучысы

### Укытучыларым!

Җир йөзендә һөнәрләр бик күп. Шулар арасында иң җаваплы һәм мактаулы һөнәрләрнең берсе- укытучы һөнәре. Ул зур сабырлык, тырышлык, балаларга карата олы мәхәббәт таләп итә. Безнең мәктәптә иң яхшы, көчле рухлы, ярдәмчел, олы җанлы, кешелекле укытучылар белем бирәләр. Дәресләргә мин бик теләп йөрим. Чөнки мине, чын мәгънәсендә, белем остазлары каршы ала. Һәр дәрес үзенчәлекле, күңелле уза. Хөрмәтле укытучыларым! Сезне һөнәри бәйрәмегез белән чын күңелемнән котлыйм. Сезгә бәхетле, озын гомер, күтәренке кәеф, эшегездә зур уңышлар, ныклы сәламәтлек телим.

Шакирова Элина,

9нчы Б сыйныф укучысы

### Яраткан укытучым!

Безнең мәктәптә зур хөрмәткә лаеклы укытучылар бик күп. Шулар арасында химия һәм биология укытучысы – Регина Фирдәүс кызы да бар. Миңа Регина Фирдәүс кызының укытуы ошый. Аның дәресләре кызыклы, мавыктыргыч, сизелмичә дә узып китә. Яшь булуына карамастан, ул бик тырыш, җаваплы һәм таләпчән укытучы. Мин Регина Фирдәүс кызына иҗади уңышлар телим. Барлык укытучыларны бәйрәм белән котлыйм!

Адылгараев Руслан,

9 нчы Б сыйныфы укучысы


# Балалар иҗаты

***Бүгенге иҗатыбыз яраткан укытучыларга багышлана***





Махиянов Марсель, 5 нче Б сыйныфы укучысы









Сөләйманова Амира, 3 нче Б сыйныфы укучысы

Калимуллина Диләрә, 6 нчы Б сыйныфы укучысы

Хабибуллина Динара, 5 нче Б сыйныфы укучысы

# Тапкырлар аланы



## Сүзләр эзләү - Үсемлекләр

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| э | й | ш | э | я | ц | н | к | ж | ж | ц | н | ы | б | о |
| э | б | й | ъ | д | к | ц | ч | ә | ъ | г | д | ш | й | ъ |
| и | т | ъ | э | р | з | я | а | б | ч | э | ю | ч | щ | и |
| ч | ч | м | р | б | ф | я | а | т | ц | ә | с | ш | х | х |
| щ | р | г | щ | т | з | н | б | з | ъ | ш | ч | р | я | ф |
| ы | е | ч | д | ю | ъ | т | ә | ж | р | п | р | л | м | ч |
| ц | т | ө | н | б | ө | е | к | л | а | ы | и | м | ө | ю |
| д | ә | ч | т | м | ы | ц | е | я | а | ж | м | е | э | г |
| з | ш | п | ц | й | с | з | ы | т | р | л | к | у | а | з |
| б | ү | х | и | т | б | щ | х | б | э | н | н | ъ | м | ю |
| м | ә | т | р | ү | ш | к | ә | й | ъ | й | и | ъ | в | а |
| е | л | л | я | и | у | э | з | ц | ъ | ы | м | ш | л | у |
| п | и | ы | б | н | н | н | л | м | й | д | с | ж | р | о |
| и | м | д | и | җ | в | ж | б | е | л | г | я | ю | и | з |
| э | щ | п | е | н | э | н | с | и | к | р | ә | н | л | л |

ТӨНБӨЕК
ГӨЛЧӘЧӘК
ЯСМИН
ЛАЛӘ
УМЫРЗАЯ
ЭНҖЕ
МИЛӘУШӘ
МӘТРҮШКӘ
НӘРКИС



Татар халык мәкален укыгыз.




**Гәҗитне басмага әзерләделәр:**

6 нчы сыйныф укучылары

Җитәкчеләре: Хөсәенова Л.Т.

***Сездән язмалар көтеп калабыз!***